КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 август г.Казань № 878

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын күтәрү турында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карары белән расланган тәртиптә билгеләнә торган Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларның күләмен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларның күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсе аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин